МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.09.2024 Казан ш № 618

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.02.2020 №70, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.05.2021 №290, 17.11.2021 №846, 04.04.2022 №254, 08.07.2022 №671, 20.01.2023 №21, 02.11.2023 №858, 27.06.2024 №456 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.09.2024 №618 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) (техник мөмкинлек булган очракта) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасындагы (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.»;

2.4.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхси кабинет аша Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) тапшырылган очракта, гаризага эш номенклатурасы һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинетта чагылдырылган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып Үзәк бүлекчәсе тарафыннан 14 эш көне дәвамында дәүләт хезмәте күрсәтелә.»;

2.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) рәсми сайтында урнаштырылган:»;

2.6.1 пунктта:

дүртенче абзацта «яки Бердәм порталда (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

егерме икенче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2.6.2 пунктның унҗиденче абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2.7.1 пунктның җиденче абзацына «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2.13.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинет аша электрон рәвештә айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында кабул ителгән карар турында хәбәр алу мөмкинлеге;»;

2.13.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша җибәргәндә, турыдан-туры бәйләнешкә керү таләп ителми.»;

2.14.2 пунктта:

«б» пунктчасында «Бердәм портал» сүзләреннән соң «(техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

«г» пунктчасында «Бердәм портал» сүзләреннән соң «(техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

«е» пунктчасында «Бердәм портал» сүзләреннән соң «(техник мөмкинлек булганда)» сүзләрен өстәргә;

2.14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать

итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта) аша җибәрелгән очракта, Административ регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта) шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.»;

2.14.6 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче бирүче айлык пособие билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, Административ регламентның 2.6.1 пунктына туры китереп, документлар күчермәләрен теркәп тапшыра.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша авторизация уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза Административ регламентның 2.6.1 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гарызнамәнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Үзәк бүлекчәсенә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша җибәрелә.»;

3.3.2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша җибәрелгән очракта).»;

алтынчы абзацны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда (техник мөмкинлек булган очракта) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта) аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла.»;

3.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Айлык пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә коруны дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнарыннан (халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләреннән) түләнә торган эшсезлек буенча пособиене алу һәм аның күләме, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләүләрне алу һәм аның күләме турында;

пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм күләмнәре турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

айлык пособие билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында (Федераль салым хезмәтеннән);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрдан);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан);

билгеләнгән тәртиптә торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында (Росреестрдан);

Россия ЭЭМ түли торган пенсияне алу һәм аның күләме турында  (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

Россия Оборона министрлыгы түли торган пенсияне алу һәм аның күләме турында (Россия Оборона министрлыгыннан);

шәхси счетның иминият номеры турында( Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмавы турында (Федераль салым хезмәтеннән).

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә (техник мөмкинлек булганда) өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүче паспортының дөреслеген раслау турында белешмәләр алына (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.»;

3.6 пунктта беренче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3.7.3 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «яки Бердәм портал (мондый техник мөмкинлек булдырылган очракта)» сүзләрен өстәргә;

Административ регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк
баласы булган, ата-анасының берсе яки
икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә)
бер генә баласы булса да инвалид булган
гаилә әгъзаларына айлык пособие
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА №_________
_________ 20__ ел.

Мин, _____________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес: ____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкиленең индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп, почта адресы)
эш итү нигезе:
_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________
Билгеләвегезне сорыйм ________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес:
_____________________________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм

аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә айлык пособие (алга таба – айлык пособие).

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Гаилә составы:

| № | Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында булмавын раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукында чикләнмәгән

____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең имзасы, тулы имзасы)

Билгеләнгән айлык пособиене хисапка күчерү юлы белән түләвегез турында сорыйм ______________________________________________
(мөрәҗәгать итүче яисә аның законлы вәкиле тарафыннан кредит оешмасында социаль түләүләрне күчерү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чараларын түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында
хәбәр итү йөкләмәсе белән таныштым ____________________________
(мөрәҗәгать итүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында да, риза:
әлеге адрес буенча язмача формада_____________________________________
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча: _________________________________
(электрон почта адресы)

________________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

___________________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

______________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

Үзәк бүлекчәсе аша «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре)» дәүләт казна учреждениесендә минем айлык пособие алу хокукымны яңа чорга раслый торган белешмәләр булган очракта, үзем мөрәҗәгать итмичә генә, айлык пособие билгеләнүенә риза

__________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында).

Мөрәҗәгать итүче:
________________________________________ _________ «___» ________ 20__ ел.
Мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә танылган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________ __________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

________________________________________________________________________

Аеру линиясе
Язу-белдерү

Гаризаның теркәлү №______________________
Документлар саны ______ данә, __ биттә.
Документларны кабул итте ___________ _________ _________ _____________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Административ регламентка 3 нче һәм 4 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм
аннан күбрәк баласы булган,
ата-анасының берсе яки икесе
дә инвалид бала булган һәм
(яисә) бер генә баласы булса да
инвалид булган гаилә
әгъзаларына айлык пособие
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсе
_____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү турында карар

№________________ _________ 20__ ел.

Билгеләргә:____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адресы: ___________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык

пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә айлык пособие.
Түләү вакыты: _________ башлап _________ кадәр
Түләү ысулы: ___________________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

________________________ __________________________________ ______________
муниципаль районында (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имза)
(шәһәр округында)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

____________________________ ______________________________ ______________
муниципаль районында (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)
(шәһәр округында)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
шәхсән _____________________,
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча: ________________________________
(электрон почта адресы)
________________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ________________________________________
_ («әйе» яки сызык куярга)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ______________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсе
______________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләүдән баш тарту турында карар

№____________ « _____» ________ 20__ ел.

Билгеләүдән баш тартырга _____________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адресы: _________________________________________,
(Почта индексы, теркәлү адресы
______________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) бер генә булса да баласы инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 елның 7 сентябрендәге 803 номерлы карары нигезендә айлык пособие.
Баш тарту сәбәбе: _______________________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
_______________________
муниципаль районда (шәһәр округында) ______________________________ __________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсе белгече
_________________________ _____________________________ ______________
муниципаль районында (шәһәр округында) (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:

шәхсән ________________________,
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
әлеге адрес буенча язмача формада___________________________________
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча: ______________________________
(электрон почта адресы)

______________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

___________________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

_____________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид бала булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

яши торган адрес: ______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп,
телефоны, электрон адресы)

_________________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең шәхесен раслаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)

техник хатаны төзәтүне сорыйм _______________________________________
_________________________________________________________________,
18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган, ата-анасының берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яисә) бер генә баласы булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән __________________________________
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны алуга риза:
әлеге адрес буенча язмача формада_________________________________
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча: _____________________________
(электрон почта адресы)

____________________________________телефонына смс-хәбәр итеп
(телефон номеры)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

_________________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

____________________________
(«әйе» яки сызык куярга)

«___» _____________ 20__ ел. ____________________ ___________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)».